**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ**
**КАРАРЫ**

**№ 2** **23 ноябрь 2019 ел**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
Районы Туйкә авыл җирлеге составына керүче
Туйкә авылында 2020 елда гражданнарның
үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге Туйкә авылында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Туйкә авыл җирлеге Туйкә торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 (Дүрт йөз) сум күләмендә, 2 группа инвалидлар, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар, күп балалы гаиләләр өчен 200 (Ике йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләүне киметеп үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлдерергә:

- Яшьләр, Гагарин, Киров урамнары юлларына вак таш (щебенка) җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);
- Туйкә авылы урамнары исемнәре язылган күрсәткечләр сатып алу;
- Туйкә авылы урамнарына яктырткычлар, махсус җиһазларны сатып алу, энергия саклаучы лампаларны урнаштыру, килешүе буенча эш өчен түләү;
- Туйкә авылында юлларны кардан чистарту;
- үзәкләштерелгән чыганаклардан эчә торган суны анализлау: «Сугышлы чишмәсе»;
- Туйкә авылында «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», «Яңа ел» бәйрәм чараларын үткәрү буенча хезмәт күрсәтү, бүләк, сувенир продукциясе сатып алу;
- Туйкә авылы юлларының техник паспортларын ясату;
- Туйкә авылы зиратларынын җир кишәрлекләрен ызанлау; җирләрнең категорияләрен үзгәртү.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Туйкә авыл җирлеге Башлыгы Закирова Р.Р.